ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

6 декабрь, 2024 ел № 39/8

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Шәһәр Советы карары проекты буенча җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләрен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьялары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93, 94 статьялары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4, 2007 елның 4 июлендәге 23/4, 2007 елның 25 декабрендәге 28/10, 2008 елның 29 февралендәге 30/7, 2009 елның 9 апрелендәге 40/6, 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7, 2010 елның 31 мартындагы 47/7, 2010 елның 27 декабрендәге 7/6, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7, 2012 елның 5 июлендәге 19/15, 2012 елның 20 декабрендәге 22/19, 2013 елның 29 августындагы 26/17, 2014 елның 21 февралендәге 29/17, 2014 елның 16 октябрендәге 33/17, 2015 елның 27 февралендәге 38/14, 2015 елның 23 июлендәге 41/11, 2016 елның 24 февралендәге 6/10, 2017 елның 22 февралендәге 15/10, 2017 елның 10 августындагы 18/9, 2017 елның 15 декабрендәге 21/16, 2018 елның 27 апрелендәге 24/8, 2018 елның 11 декабрендәге 28/9, 2019 елның 1 августындагы 32/13, 2019 елның 6 декабрендәге 34/14, 2020 елның 17 июнендәге 40/3, 2020 елның 29 декабрендәге 4/7, 2021 елның 27 маендагы 7/6, 2021 елның 3 ноябрендәге 9/5, 2022 елның 23 июнендәге 15/6, 2022 елның 26 декабрендәге 19/7, 2023 елның 5 маендагы 23/4, 2023 елның 25 октябрендәге 27/8, 2024 елның 2 маендагы 33/7 номерлы Карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) **9 статьяның 1 өлешендә түбәндәге эчтәлекле 46 пункт өстәргә:**

«46) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуны хуҗалык кенәгәләрендә гамәлгә ашыру»;

2) **12 статьяның 9 өлешендәге икенче абзацта** «башка иҗтимагый оешмаларның» сүзләрен төшереп калдырырга, «җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләрен «тиешле референдум комиссиясе» сүзләренә алыштырырга, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма органы» сүзләренә алыштырырга;

3) **28 статьяның 2 өлеше 52 пунктында** «муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) **32 статьяның 2 өлешендә** түбәндәге редакциядә 10.1 пункт өстәргә:

10.1.) «чит ил агенты статусына ия булганда»;

5) **35 статьяның 1 өлеше 26 пунктындагы 4 абзацын** көчен югалткан дип танырга;

6) **41 статьяның 1 өлешендә** түбәндәге редакциядә 1.1 пункт өстәргә:

«1.1) әгәр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында, әлеге Уставта башкасы каралмаган булса, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәткәрләренең, шулай ук акцияләренең (өлешләренең) йөз проценты муниципаль берәмлеккә караган хуҗалык җәмгыятьләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү күләмнәрен һәм шартларын билгеләү;»;

7) **41 статьяның 1 өлешендә** түбәндәге редакциядә 8.1 пункт өстәргә:

«8.1) муниципаль берәмлек тарафыннан капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында килешүләр төзү шартларын һәм тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актлар кабул итү;»;

8.2) капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турындагы килешүне өзү нигезләре булуны күрсәтә торган хәлләрне тикшерүне үз эченә ала торган мониторингны гамәлгә ашыру;»;

8) **41 статьяның 2 өлешендә** түбәндәге редакциядә 2.1 пункт өстәргә:

«2.1 Россия Федерациясенең электроэнергетика турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда муниципаль милектәге электр челтәре хуҗалыгы объектларын Россия Федерациясе субъекты чикләрендә эшләүче система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасына яисә территориаль челтәр оешмасына түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыру»;

9) **41 статьяның 4 өлешендә** түбәндәге эчтәлекле 17.1 пункт өстәргә:

«17.1) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуны хуҗалык кенәгәләрендә гамәлгә ашыру»;

10) **41 статьяның 9 өлешендә** 24.2 – 24.4. пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24.2) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен, шул исәптән юл хәрәкәте мониторингын оештыру;

24.3) региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында урнашкан гомуми файдаланудагы парковкалардан тыш, шәһәр территорияләрендә урнашкан гомуми файдаланудагы парковкалар реестрын алып бару;

24.4) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын урнаштыруны, алыштыруны, демонтажлауны һәм карап тотуны тәэмин итү;»;

2. Әлеге Карар, үз көченә керү гамәлдәге законнар белән башка вакытта каралган аерым нигезләмәләреннән тыш, матбугатта рәсми басылган көннән үз көченә керә.

3.Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г. Мәһдиевка әлеге Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә тапшырырга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Россия Федерациясе Юстиция Министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2024 елның 16 декабрендә теркәлде. Дәүләт теркәве номеры RU163020002024002.